СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**Яңа Кишет авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**« 21 » декабрь 2018 ел** **№ 21**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлегендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясына таянып, гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 октябрендәге 11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халык тыңлаулары халык, Яңа Кишет авыл җирлеге Советы (алга таба - Совет), Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы (алга таба - башлык) яисә контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә.

2) 5 статьяның 1 өлешендәге 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы яки контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә торган гавами тыңлаулар Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә».

2. Әлеге карарны Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып .

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Т.А.Арсланов